АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.04.2019 п.г.т. Алексеевское № 246

**“Хезмәттә (вазыйфада) үз-үзеңне тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешләрен җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәне раслау хакында” Алексеевск муниципаль районы Советының 22.06.2018 ел, 176 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында**

“Коррупциягә каршы көрәшү турында законнарның үтәлеше өчен контрольне көчәйтү максатында Россия Федерациясе Президентының кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Россия Федерациясе Президентының 19 сентябрь, 2017 ел, 431 нче Указы, “Коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының кайбер указларына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Президентының 11 декабрь, 2017 ел, УП-1092 санлы Указы нигезендә

**Алексеевск муниципаль районы Совет карар бирде:**

1. “Хезмәттә (вазыйфада) үз-үзеңне тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешләрен җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәгә “Хезмәттә (вазыйфада) үз-үзеңне тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешләрен җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәне раслау турында” Алексеевск муниципаль районы Советының 22.06.2018 ел, 176 нчы карары белән расланган үзгәрешләрне кертергә һәм аларны түбәндәге эчтәлектәге 3.2.6 пункты белән тулыландырырга:

Әлеге Нигезләмәнең 3.2.3 һәм 3.2.4 пунктларында каралган дәлилле нәтиҗәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты "б" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм "д" пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яки хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) запрослар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты "б" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм "д" пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яки хәбәрнамәләрне алдан карау йомгаклары буенча дәлилле нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең яисә башка карарның 3.9, 3.10.3, 3.11.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен кабул итү өчен тәкъдимнәр".

2. "Хезмәттә (вазыйфада) үз-үзеңне тоту, муниципаль вазыйфалар биләүче вазыйфаи затларның үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында мәнфәгатьләр бәрелешләрен җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәне раслау турында" 19.07. 2016 ел, 50 нче санлы "Алексеевск муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында" 19 апрель, 2018 ел, 152 нче санлы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советы карарын көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Совет рәисе урынбасары Г.В. Беловага йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**